КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 сентябрь г.Казань № 1135

Питрәч муниципаль районы, Питрәч авылы, Вишневая урамы, 5 нче йорт адресы буенча күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау эшләре исемлеге һәм аларның иң чик рөхсәт ителгән кыйммәте турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 6 өлеше, Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 5 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган мәсьәләләр буенча карар кабул итү тәртибе нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 5 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган мәсьәләләр буенча, авария, табигый һәм техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта, карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 12 октябрь, 787 нче карары белән расланган Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 5 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган мәсьәләләр буенча, авария, табигый һәм техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта, карар кабул итү тәртибе нигезендә, Питрәч муниципаль районы, Питрәч авылы, Вишневая урамы, 5 нче йорт адресы буенча күпфатирлы йортта гадәттән тыш хәл салган зыяннарны бетерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Питрәч муниципаль районы, Питрәч авылы, Вишневая урамы, 5 нче йорт адресы буенча күпфатирлы йорттагы (алга таба – күпфатирлы йорт) уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау – түбәне ремонтлау эшләре исемлеген;

күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау эшләренең иң чик рөхсәт ителгән кыйммәтен 3 980,585 мең сум күләмендә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин